**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422701, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Высокая Гора, ул. Юбилейная, 1А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Юбилей ур., 1А

тел./факс 8(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**22 апрель, 2021 ел** **№ 14**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^{3}$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ**:**

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен расларга.

2. Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 3 нче районара инспекциясенә 1 сентябрьгә кадәр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елы өчен, хисап елына кадәрге ел өчен түбәндәге белешмәләрне җибәрергә тәкъдим итәргә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге бюджетының төшеп калган керемнәре суммалары турында;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең һәр салым чыгымы буенча.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.К.Мингазов

Кушымта
Расланды
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 22 апрелендәге 14 нче номерлы карары белән

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү (алга таба - Тәртип, муниципаль берәмлек) кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары (алга таба - гомуми таләпләр) белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр белән билгеләнгән терминнар һәм төшенчәләр кулланыла

3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан, муниципаль программаларның структур элементларыннан һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

1. 4. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында муниципаль берәмлек башкарма комитеты:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзи;

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра.

## II. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзү

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан төзелә һәм агымдагы елның 1 июненә кадәр раслана.

6. Муниципаль берәмлекнең расланган Салым чыгымнары исемлеге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында (авыл җирлекләре бүлегендә) агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

7. Ел саен муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты хисап финанс елы өчен һәм хисап елыннан алдагы ел өчен Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 3 нче районара инспекциясеннән (алга таба – РФ ТР

буенча ФНС N3 МРИ) ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында, муниципаль берәмлек бюджетының һәр салым чыгымнары буенча муниципаль берәмлек бюджетының төшеп калган керемнәре суммалары турында һәр елны мәгълүмат соратып ала.

8. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру максатларында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты ел саен, 1 августка кадәр, РФ ТР буенча ФНС N3 МРИнән, муниципаль берәмлекнең тиешле салым чыгымнарын, шул исәптән хисап елында һәм алдагы хисап елында гамәлдә булган норматив хокукый актларын һәм әлеге Тәртипкә кушымтада каралган башка мәгълүматны күрсәтеп, түләүчеләр категорияләре турында белешмәләр җибәрә.

9. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә кертелгән мәгълүматны үзгәртүне күздә тоткан норматив хокукый актлар кабул ителгән очракта, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тиешле норматив хокукый акт үз көченә кергән көннән соң 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертә.

## III. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү тәртибе.

10. Салым чыгымнарын бәяләү муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне кертә:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары күләмнәрен бәяләү;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү.

11. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- муниципаль берәмлек салым чыгымнарының максатка ярашлы булуын бәяләү;
- муниципаль берәмлек салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү.

12. Муниципаль берәмлек салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына, муниципаль программаларның структур элементларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләрнең саны һәм бишьеллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана торган салым ташламаларына салым түләүчеләрнең ихтыяҗы булуы.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә туры килмәгән очракта да, муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына түләүчеләр өчен ташламаларны саклап калу (төгәлләштерү, бетерү) турында тәкъдимнәр тапшырырга кирәк.

13. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының нәтиҗәлелеге критерие буларак муниципаль программа максатларына яисә муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең кимендә бер күрсәткече (индикаторы) яисә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары йогынты ясый торган башка күрсәткеч (индикатор) билгеләнә.

Әлеге күрсәткеч (күрсәткечләр) хисап елына, хисап елына кадәрге елга, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына билгеләнә.

Түләүчеләр өчен каралган ташламаларның муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлек социаль-икътисадый сәясәтенең муниципаль программаларга карамаган максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторның) үзгәрүенә керткән өлеше бәяләнергә тиеш, ул әлеге күрсәткечнең (индикаторның) ташламаларны исәпкә алып һәм күрсәтелгән күрсәткечнең (индикаторның) ташламаларны исәпкә алмыйча аермасы буларак исәпләнелә.

14. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.

15. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына кермәгән социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенә һәм ташламалар бирү нәтиҗәлелегенә чагыштырмача анализ ясала.

16. Чагыштырма анализ муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына ирешүнең һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлек социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын кулланган очракта муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары күләмнәрен һәм бирелгән ташламаларның күләмен чагыштыруны үз эченә ала (муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткечләре (индикаторы), муниципаль берәмлек программаларының салым чыгымнарының 1 сумга һәм шул ук күрсәткечкә (индикаторга) ирешү өчен альтернатив механизмнар кулланылган очракта муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының 1 сумга артуын исәпләү).

Муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнары сыйфатында муниципаль берәмлектә түбәндәгеләр исәпкә алынырга мөмкин:

а) муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән ташламаларга хокуклы түләүчеләргә турыдан-туры финанс ярдәменең субсидияләр яисә башка рәвешләре;

б) ташламаларга хокукы булган түләүчеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләр бирү;

в) ташламаларга хокуклы түләүчеләр эшчәнлеге өлкәсендә контроль-күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыру нормативларын җайга салуны һәм (яисә) тәртибен камилләштерү.

17. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү 1 октябрьгә кадәр гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- салым чыгымнарын бәяләүне уздыру өчен күрсәткечләр исемлеге буенча мәгълүмат;

- салым чыгымнарының максатчан характеристикаларына ирешү (ирешмәү) турында, муниципаль программа һәм (яисә) социаль-икътисадый сәясәт максатларына ирешүгә салым чыгымнарының өлеше турында нәтиҗәләрне үз эченә алган язма аңлатмалар;

- аларга ирешү өчен нәтиҗәлерәк альтернатив механизмнар булу (булмау) турында тәкъдимнәр;

- салым чыгымнарын саклау, төгәлләштерү (гамәлдән чыгару), яңа салым чыгымнарын билгеләү буенча тәкъдимнәр.

18. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Кушымта
Салым чыгымнары
исемлеген төзү тәртибенә

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге салым чыгымнарын бәяләү өчен күрсәткечләр исемлеге**

| Күрсәткечнең исеме | | Мәгълүматлар чыганагы |
|---|---|---|
| **I. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының норматив һәм максатчан характеристикалары** | | |
| 1. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 2. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 3. | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 4. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 5. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлдә була башлау көне | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 6. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 7. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату көне | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 8. | Салым ташламалары, азат итүләр һәм салымнар буенча башка преференцияләр аталышы | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 9. | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (стимуллаштыручы яисә техник ташламалар ясаучы социаль ярдәм) | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламалары, азат итүләр һәм салым түләүчеләр өчен башка преференцияләр бирү максатлары | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 11. | Салым ташламалары, азат итү һәм муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән башка преференцияләр каралган салымнар исемнәре | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 12. | Түләүчеләрнең аерым категорияләренә башка түләүчеләр белән чагыштырганда өстенлекләрне билгели торган салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм башка преференцияләрнең төре, | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 13. | Салым ташламалары, азат итү һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирелә торган салым ставкасы күләме | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 14. | Салым ташламалары, азат итүләр һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирүгә бәйле рәвештә дәүләт программаларына карамаган муниципаль программаларның һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәтенең максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| **II. Салым чыгымнарының фискаль характеристикалары** | | |
| 15. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары нигезендә салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләме хисап елына кадәрге елда һәм хисап елында (мең сум) | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 3 нче районара инспекциясе |
| 16. | Агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләмен бәяләү (мең сум) | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 17. | Муниципаль берәмлекнең хокукый актларында билгеләнгән салым ташламасыннан, башка преференциядән (берәмлекләрдән) файдаланучы салым түләүчеләр саны | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 3 нче районара инспекциясе |
| 18. | Салым чыгымнарының эффективлыгын бәяләү нәтиҗәсе | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |